ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ

# Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозган өчен җаваплылык билгели торган Татарстан Республикасы закон актлары



КАЗАН, 2010

# Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозган өчен җаваплылык билгеле торган Татарстан Республикасы закон актлары

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе, юридик фәннәр кандидаты, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган юристы Яһудин Шакир Шәяхмәт улы редакциясендә

Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозган өчен җаваплылык билгели торган Татарстан Республикасы закон актлары – Казан: Татарстан Республикасы Дәүләт Советы басмасы, 2010.

# Кереш сүз

Көчле тавышның кеше организмына тискәре йогынты ясавы, төрле авыруларга, социаль конфликтларга китерүе һәркемгә мәгълүм. Хәзерге урбанизация гасырында тирә-юньдәге көчле тавыштан читтә калу мөмкин түгел. Бары тик өй шартларында гына без артык децибеллардан ял итә алабыз. Ләкин, әгәр өй янәшәсендә күңел ачу үзәге яисә төзелеш мәйданы булса, тавыш монда да комачауларга мөмкин.

Төнлә гражданнарның тынычлыгын саклау буенча эш элек тә алып барылды. Ләкин бу мәсьәләне төгәл хәл итә торган закон булмады, ә булган санкцияләр артык түбән иде. Мәсәлән, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.8 статьясында төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозган өчен кисәтү рәвешендә яисә 300 сумнан алып 500 сумга кадәр штраф рәвешендә җаваплылык каралган иде. Мондый санкцияләр тиешле нәтиҗәне бирмәде. Өстәвенә шундый ук хокук бозуларны кабатлаган өчен җаваплылык бөтенләй каралмаган иде.

2010 елның гыйнварында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Ш.Ш. Яһудин һәм Р.Г. Ногмановның закон чыгару инициативасы белән «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителде, аның максаты – төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны боза торган зарарлы тавыш йогынтысының тышкы чыганакларыннан гражданнарны яклауны хокукый җайга салуның камилрәк механизмын булдыру.

Закон нигезендә төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозуга китерә торган итеп ремонт, төзелеш, төяү-бушату эшләрен башкарудан күпфатирлы һәм индивидуаль торак йортлар гына түгел, аларда урнашкан гомуми файдалану урыннары да яклана. Тынлыкны сырхауханәләрдә, диспансерларда һәм башка медицина учреждениеләрендә, шифаханәләрдә, ял йортларында, пансионатларда, балалар тәүлек буе була торган мәгариф учреждениеләрендә, балалар, өлкән гражданнар һәм инвалидлар өчен интернат йортлар урыннарында; кунакханәләр номерлары һәм тулай торакларның торак бүлмәләрендә; йорт яны территорияләрендә; кемпингларда, мотельләрдә, ял базалары территорияләрендә; бакчачылык, яшелчәчелек һәм коммерциячел булмаган дача берләшмәләре территорияләрендә саклау зарур.

Шул ук закон чыгару инициативасы нигезендә бер үк вакытта Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.8 статьясына да үзгәрешләр кертелде. Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозучы гамәлләрдән гражданнарны яклауга катгый контроль һәм дифференциацияләнгән хокукый механизм күздә тотыла. Мондый гамәлләр өчен административ җаваплылык гражданнарның, вазыйфаи һәм юридик затларның категорияләре буенча билгеләнә, гражданнарга кисәтү ясала һәм биш йөздән алып бер мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – биш меңнән алып ун мең сумга кадәр; юридик затларга егерме меңнән алып илле мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

Карала торган иҗтимагый мөнәсәбәтләр өлкәсендә кабат хокук бозган өчен административ җаваплылык билгеләү законның яңалыгы булып тора. Шушы гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган өчен күрсәтелгән затларга зуррак күләмдә административ штраф салына.

Әлеге законнарны гамәлгә ашыру механизмын көчәйтү максатында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы 2010 елның 12 мартында «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» карар кабул итте.

Татарстан Республикасы Россия Федерациясендә беренчеләрдән булып төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклауны регламентлый торган закон кабул итте. Законны җайга салу мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына гражданнардан мөрәҗәгатьләр даими килеп тора. Без аларны игътибар белән анализлыйбыз, шулай ук күрсәтелгән законнарны гамәлгә ашыру белән шөгыльләнәбез, ягъни Татарстан Республикасында төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклауны законлы җайга салу практикасын алга таба да камилләштерү йөзеннән аларның мониторингын гамәлгә ашырабыз.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе, юридик фәннәр кандидаты Ш.Ш. Яһудин**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

# Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2009 елның 24 декабрендә
кабул ителде

## 1 статья. Әлеге Законның җайга салу предметы

1. Әлеге Законның җайга салу предметы төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны тәэмин итүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрдән гыйбарәт.

2. Әлеге Законның гамәлдә булуы түбәндәгеләргә кагылмый:

1) юридик затларның һәм гражданнарның хокукка каршы гамәлләрне булдырмый калуга, һәлакәтләрне, табигый бәла-казаларны, бүтән гадәттән тыш хәлләрне булдырмый калуга һәм аларның нәтиҗәләрен бетерүгә, янгыннарны сүндерүгә юнәлдерелгән, гражданнарның иминлеген тәэмин итүгә яисә халыкның тормышын тәэмин итү объектларының эшләвенә бәйле кичектергесез эшләр башкаруга, оборона гамәлләрен (шул исәптән гражданнар оборонасы һәм мобилизация буенча гамәлләрне) үтәүгә, дәүләтнең оборона сәләтен һәм иминлеген тәэмин итүгә, җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген саклауга, гражданнарны коткаруга, аларның гомеренә яисә сәламәтлегенә янауны бетерүгә юнәлдерелгән гамәлләренә;

2) юридик затларның һәм гражданнарның тиешле конфессияләрнең канун таләпләре кысаларында дини йолаларны башкаргандагы гамәлләренә;

3) законнар белән билгеләнгән эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә бәйрәм итүгә бәйле рәвештә юридик затларның һәм гражданнарның гамәлләренә;

4) билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәдәни чаралар үткәрүгә бәйле гамәлләргә, шулай ук гомумфедераль, республика һәм муниципаль дәрәҗәдәге күренекле вакыйгаларны бәйрәм итүгә бәйле рәвештә массакүләм чаралар уздыруга бәйле гамәлләргә;

5) административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе законнарында административ җаваплылык билгеләнгән гамәлләргә.

2 статья. **Төнге вакыт**

Әлеге Закон максатларында төнге вакыт дип 23.00 сәгатьтән алып 6.00 сәгатькә кадәр вакыт аңлашыла.

3 статья. **Төнлә гражданнарның тынычлыгы һәм тынлык тәэмин ителә торган объектлар**

Төнлә гражданнарның тынычлыгы һәм тынлык тәэмин ителә торган объектлар түбәндәгеләр:

1) күпфатирлы һәм индивидуаль торак йортлар, шул исәптән аларда урнашкан гомуми файдалану урыннары;

2) сырхауханәләр, диспансерлар һәм башка медицина учреждениеләре, шифаханәләр, ял йортлары, пансионатлар, балалар тәүлек буе була торган мәгариф учреждениеләре, балалар, өлкән гражданнар һәм инвалидлар өчен интернат йортлар урыннары;

3) кунакханәләр номерлары һәм тулай торакларның торак бүлмәләре;

4) йорт яны территорияләре;

5) кемпинглар, мотельләр, ял базалары территорияләре;

6) бакчачылык, яшелчәчелек һәм коммерциячел булмаган дача берләшмәләре территорияләре.

4 статья. **Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны боза торган гамәлләр**

Әлеге Законның 3 статьясында санап үтелгән объектларда төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны боза торган түбәндәге гамәлләрне кылу тыела:

1) төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозуга китерә торган итеп телевизорларны, радиоалгычларны, магнитофоннарны һәм башка тавыш чыгара торган җайланмаларны, шулай ук тавыш көчәйткеч җайланмаларны, шул исәптән транспорт чараларында, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларын-

да һәм куңел ачу үзәкләрендә урнаштырылганнарны куллану;

2) берничә мәртәбә эшләп киткән саклау сигнализациясенең тавыш сигналларын вакытында сүндермәү, шул исәптән транспорт чараларында урнаштырылганнарын да, йә төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозуга китерә торган итеп төзек булмаган саклау сигнализациясен куллану;

3) төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозуга китерә торган итеп пиротехник чараларны куллану;

4) төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозуга китерә торган итеп музыка коралларында уйнау, кычкырулар, сызгыру, җырлау, шулай ук тавыш чыгара торган бүтән гамәлләр;

5) төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозуга китерә торган итеп ремонт, төзелеш, төяү-бушату эшләрен башкару.

5 статья. **Административ җаваплылык**

Әлеге Закон нигезләмәләрен бозуда гаепле затлар Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә җаваплы булалар.

6 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш. Шәймиев**

Казан, Кремль
2010 елның 12 гыйнвары
№ 3-ТРЗ

2006 елның 9 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы

# АДМИНИСТРАТИВ ХОКУК БОЗУЛАР ТУРЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОДЕКСЫ

(07.11.2007 № 45-ТРЗ, 08.11.2007 № 49-ТРЗ, 05.02.2009 № 12-ТРЗ, 29.07.2009 № 33-ТРЗ, 22.10.2009 № 49-ТРЗ, 26.12.2009 № 70-ТРЗ, 12.01.2010 № 4-ТРЗ Татарстан Республикасы законнары редакциясендә)

**(өземтә)**

3.8 статья. **Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозу**

Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозган өчен –

кисәтү ясала яисә гражданнарга – биш йөздән алып бер мең сумга кадәр, вазыйфаи затларга – биш меңнән алып ун мең сумга кадәр, юридик затларга егерме меңнән алып илле мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

Шушы гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган өчен -

гражданнарга – бер мең ярымнан алып ике мең сумга кадәр, вазыйфаи затларга – унбиш меңнән алып егерме мең сумга кадәр, юридик затларга алтмыш меңнән алып җитмеш мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

---

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

# «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре Л.Н. Маврина «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, шулай ук Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозган өчен җаваплылык билгеләүгә кагылышлы аерым статьяларын аерым брошюра итеп Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бастырып чыгаруны оештырырга тиеш.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, шулай ук Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозган өчен җаваплылык билгеләүгә кагылышлы аерым статьяларын гамәлгә ашыру буенча тиешле чаралар күрергә тиеш.

3. Җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

«Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, шулай ук Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозган өчен җаваплылык билгеләүгә кагылышлы аерым статьяларының эчтәлеген халыкка җиткерергә, шул исәптән плакатлар, баннерлар, башка күргәзмә мәгълүмат аша да;

«Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру тәртибен аңлату буенча системалы эш оештырырга.

4. «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгына, «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе ААҖ белән, башка республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чаралары белән берлектә, «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, шулай ук Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозган өчен җаваплылык билгеләүгә кагылышлы аерым статьяларын гамәлгә ашыру барышын массакүләм мәгълүмат чараларында даими яктыртуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының гамәлгә ашырылуы турында 2010 елның декабрендә мәгълүмат тапшыруны йөкләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары А.П. Гусевка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2010 елның 12 марты
№ 769-IV ДС